| | |
|---|---|
| СОВЕТ МАМАДЫШ-АКИЛОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ МАМАДЫШ-ӘКИЛ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** Мамадыш-Әкил **КАРАР**

**2024 елның "18" ноябре** ав. **№184**

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Мамадыш-Әкил авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җир эшләре башкаруга ордер (рөхсәт) бирү буенча вәкаләтләренең бер өлешен Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенә тапшыру турында.

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 4 өлеше нигезендә Зеленодольск муниципаль районының Мамадыш-Әкил авыл җирлеге Советы карар чыгарды:

1. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Мамадыш-Әкил авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җир эшләре башкаруга ордер (рөхсәт) бирү вәкаләтләренең бер өлешен Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенә тапшырырга.

2. Зеленодольск муниципаль районы җирлегенең Мамадыш-Әкил авыл башкарма комитетына Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты белән әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән вәкаләтләрне тапшыру турында килешү төзергә.

3. Вәкаләтләрнең бер өлешен гамәлгә ашыру ел саен Мамадыш-Акил авыл җирлеге бюджетыннан Зеленодольск муниципаль районы бюджетына бирелә торган бюджетара трансфертлар хисабына башкарыла.

4. «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Мамадыш-Әкил авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җир эшләрен гамәлгә ашыруга рөхсәт бирү буенча вәкаләтләренең бер өлешен Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенә тапшыру турында» 2024 елның 05 апрелендәге 162 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә, шулай ук түбәндәге адреслар буенча мәгълүмат стендларында: Мамадыш-Әкил авылы, Ленин

урамы, 50 йорт (җирлек администрациясе бинасы), Татар Танае авылы, Үзәк урам, 1а йорт (авыл мәдәният йорты бинасы), Паново авылы, Үзәк урам, 26в йорт (авыл клубы бинасы).

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Мамадыш-Әкил авыл Җирлек башлыгы,
Совет рәисе: Ф.Ф.Мирхәтуллин